ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

с. Большие Меми

03.12.2019　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　50

Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлегендә
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 30 ноябрендәге 1нче номерлы, 2019 елның 1 декабрендәге 2,3нче номерлы гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　Г.А. Фомина

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 3 декабрендәге
50нче номерлы карарына

1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Бу тәртип Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 31 октябренә кадәр Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә гражданнар җыенында катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 1 төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары,

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү

белән (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашыру яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының https://uslugi.tatarstan.ru/ ссылкасы аша башкарыла.

8. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 3 декабрендәге
50нче номерлы карарына
1нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И. О.
______________________________________________________________________
Адресы: ______________________________________________________________
Сезгә _____________________________________нигезендә ___________________
вакытында кадәр ________________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр _________________ сум түбәндәге реквизитлар
буенча__________________________________________ түләргә кирәк.
Алучының банк БИК _____________________________
Сч. № ______________________________
Алучының сч. № ___________________________________
ИНН ___________________________________
КПП ___________________________________
КБК ________________ ОКАТО______________
Түләү билгеләү
__________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________
(имза) (имзаны роасшифровкалау)

М. у.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
_____________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
бюджетына үзара салым буенча ________________ суммада бер тапкыр түләү турында
Түләүченең Ф.И.О. ___________________________________
Адресы: ______________________________________________________________
Алган «__» ________________ 20__ ел___________________
( түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Аермалы кәгазь тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылса _______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала*